МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.11.2024 Казан ш. № 21-95-322

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 01.11.2019 ел, № 21-95-261 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Бо е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 01.11.2019 ел, № 21-95-261 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының карар кабул итү тәртибенә (Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгының 14.05.2020 ел, № 21-95-85, 29.12.2023 ел, № 21-95-413 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктында:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) «бөлгенлек (банкротлык) турында " 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын-күрсәтелгән Федераль закон нигезендә түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә – тәмамлау;»;

«$б^1$» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

«г» пунктчасында «ярлыкау турында» сүзләрен «ярлыкау актларын» сүзләренә алмаштырырга, «, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә» сүзләрен өстәргә;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча түләтүчегә башкару документын кире кайтарганда, банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаган күләмдә бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узмаган булса, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствосының тәмамлануы турында карар чыгару;»;

түбәндәге эчтәлектәге «$д^1$» пунктчасын өстәргә:

«$д^1$) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында кире кайтару турында гаризаны суд тарафыннан акт кабул ителү;»;

4 пунктта:

«а» пунктчасында «хисаптан өземтәләрне» сүзләрен "белешмәләрне" сүзенә, «(алга таба – Өземтә) " сүзләрен «(алга таба – хисаптанн белешмә)" сүзләренә алмаштырырга»;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр, алар буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган, Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Бюджет керемнәре администраторының әлеге бурычны түләтүне гамәлгә ашыручы бүлеге тарафыннан тапшырылган белешмәләре (алга таба – белешмә);»;

5 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хисаптан белешмәләр;»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) конкурс производствосын тәмамлау яки гражданның, шәхси эшмәкәкрнең мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд актын, граждан судтан тыш тәртиптә банкрот дип танылган очракта, судтан тыш тәртиптә гражданның банкротлык процедурасын тәмамлау турында Банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан алынгаан мәгълүматлар торучы документны, шулай ук аны банкрот дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә, физик зат – шәхси эшмәкәр буларак, эшчәнлеген туктату турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлардан торучы документны.»;

5[1] пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хисаптан белешмәләр;»;

7 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хисаптан белешмәләр;»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) штраф яки суд акты рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында акт яки ярлыкау акты, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә.»;

8 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) справки из отчетности;»;

«в» пунктчасында «кире кайтарылуга бәйле рәвештә» сүзләрен «кайтарылганда» сүзләренә алмаштырырга»;

«г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

$8^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$. Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «д1» пунктчасында күрсәтелгән очракта бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) хисаптан белешмәләр;

б) белешмәләр;

в) бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтару яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында суд акты – банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле.»;

түбәндәге эчтәлектәге $8^2$ пунктын өстәргә:

«$8^2$. Әлеге Тәртипнең 2 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән очракта бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) хисаптан белешмәләр;

б) белешмәләр;

в) "Башкару производствосы турында"2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча, башкару документын түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә

башкару эшен тәмамлау турында суд приставы карары һәм теркәү органы карары буенча күрсәтелгән Бюджет реестрында түләүләр түләүчене – юридик затны төшереп калдыру турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәглүматлар торучы документ нигезендә».»;

9 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хисаптан белешмәләр;»;

Әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта атамасында «ХИСАПТАН өземтә» сүзләрен «БЕЛЕШМӘ» сүзенә алмаштырырга.

Министр в. б. М.Д.Фәйзрахманов